Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 5 (5)

3 ноябрь 2011 ел

## Ике авыз сүз

31 октябрь көнне Университет тарихы музеенда үткәрелгән чираттагы ректорат утырышының көн тәртибенә түбәндәге мәсьәләләр куелган иде: 2012 елга студентлар кабул итү турында мәгълүмат, КФУның Үсеш программасын тормышка ашыруның барышы, Мәгълүмати технологияләр һәм хисаплау математикасы институтының Үсеш программасы белән танышу h.б.

Беренче булып кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе С.Ионенко чыгыш ясады. Аның сүзләренчә, алдагы кабул итү кампаниясе гадиләрдән булмаячак. Демографик хәл вузлар арасында абитуриентлар өчен үзара көрәш китереп чыгарырга мөмкин. Шуңа күрә тиешле чараларны күрергә кирәк. 10 ноябрьгә кабул итүнең контроль саннары, имтиханнар исемлеге h.б. документлар әзер булырга, ә 14 ноябрьгә институтларда кабул итүгә бәйле уздырылачак чаралар исемлеге тапшырылырга тиеш. Бу чаралар арасында мәктәпләрнең педагогик коллективлары белән хезмәттәшлек, КФУның Педагогика һәм психология институты һәм кабул итү комиссиясе тарафыннан эшләнгән «Педагогик кадрларны әзерләүдә максатчан рәвештә кабул итү» программасын тормышка ашыру һәм РФнең 30 төбәгеннән 15 меңгә якын укучы катнашачак фән олимпиадалары аерым урын алып тора.

Икътисад һәм стратегик үсеш буенча проректор М.Сафиуллин КФУның Үсеш программасы турында: «Аның үтәлеше штатлы режимда бара», – диде. Тик кыенлыклар да бар: уку, лаборатор һәм офис җиһазлары стандартлары эшләнмәгән, ә интерактив такталар һәм компьютер техникасы конфигурациягә туры килми. И.Гафуров КФУ бүлекләренә, киләчәктә мондый хәл килеп чыкмасын өчен, техник йөкләмәләр төзергә тәкъдим итте.

Мәгълүмати технологияләр һәм хисаплау математикасы институты директоры Р.Латыйпов сүзен институтның уңышларын санаудан башлап, алга таба кимчелекләргә күчте. Кадрларга бәйле кайбер проблемалар, тиешле лаборатор база булмау телгә алынды. Ректор Р.Латыйповка әлеге сорауларны эксперт комиссиясенә чыгарырга кушты. Шулай ук ул институт вәкилләрен университетның төрле программаларын тормышка ашыруда актив катнашырга һәм шушы профиль буенча эшли торган оешмалар белән хезмәттәшлек итәргә чакырды.

• • • •

Шул ук көнне вуз җитәкчелеге белән I курс аспирантлары очрашты. Яңа аспирантларны ректор Илшат Гафуров кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырулары белән котлады һәм аларның федераль университетта беренче аспирантлар булуын ассызыклады. Быел аспирантлар саны арткан, 357 кеше кабул ителгән. И.Гафуров фән белән шөгыльләнү өчен яна шартлар тудырылуын әйтте: «Диссертация темаларын сайлаганда, аларның гамәлдә кулланылышына игътибар итсәгез иде. Аспирантура өчен бирелгән вакытны дөрес файдаланыгыз. Сез моннан, ким дигәндә, фән кандидаты дипломнары алып чыгарга тиеш», – диде.

• • • •

31 октябрь көнне университетта Бөтенроссия Конфуций институты форумы ачылды. Россиядәге барлык институтларның вәкилләре Россиядә кытай телен укыту методикасын һәм Конфуций институтының үсешен өйрәнергә җыелды. Бүгенге көндә Россиядә 17 Конфуций институты, ә Кытайда 10 рус теле үзәге эшли. Дөньяда барлыгы 57 Конфуций институты һәм 479 Конфуций классы бар.

• • • •

9-10 ноябрь көннәрендә Казанда беренче мәртәбә «Продуктив фикерләү үсеше» дигән тренинг уздырыла. Аны Александра Кочеткова алып барачак. Монда вакытны дөрес бүләргә, фикерләү сәләтен үстерергә, төрле шартларда үз-үзеңне ничек тотарга өйрәнергә мөмкин. Тренингта катнашу өчен, 9 мең сум түләргә кирәк. МВА программасын үзләштерүчеләр өчен 10% ташлама. Тренинг тәмамлангач, КФУ сертификаты тапшырыла. Теркәлү өчен телефон: 299-51-93, 264-28-81, электрон адрес: mba@kfei.ru.

*ksu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# Дөнья киңлегендә - дин

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

1 ноябрь көнне Казан университетында «Мультимәдәни дөньяда ислам дине» дигән Халыкара фәнни форум ачылды. Форумны Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институты Мәскәүнең Мәрҗани фонды белән берлектә уздырды.

Мондый төр чара Казанда беренче тапкыр уздырылуына карамастан, бик зур аудиториянең җәлеп итте. Бирелдә Россия төбәкләреннән генә түгел, хәтта Үзбәкстан, Казакъстан, Төркия, Грузия, Иран, Малайзия, Пакистан, Босния һәм Герцеговинадан 200ләп алдынгы белгеч җыелды. Форумны уздыру өчен Казанны сайлау да юкка түгел, чөнки Казан университеты мөселман халыклары күпләп яшәгән Көнчыгышны өйрәнү үзәге булып тора.

Форумга җыелган кунакларны сәламләп, тышкы элемтәләр буенча проректор, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры Линар Латыйпов: «Җөмһүриятебездә исламны өйрәнүнең нигезе ныклы. Форум кысаларында исламны өйрәнүчеләр «түгәрәк өстәл»ләр, секцион утырышлар вакытында төрле актуаль проблемалар һәм сорауларны күтәрә алачак», – диде.

Татарстанның Дәүләт Советы 90нчы еллар башында беренчеләрдән булып дини оешмалар һәм сүз иреген бәйле законны кабул итте. «Без бик күп дини оешмалар белән хезмәттәшлек итәбез, бергә төрле чаралар үткәрәбез. Казанда мондый чаралар уздырылу безнең тәҗрибәнең дөньякүләм кызыклы булуы турында сөйли. Җөмһүриятебез төрле конфессия вәкилләренең дус һәм бердәм яшәве белән башкаларга үрнәк булып тора», – диде Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Президиум әгъзасы, Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев.

Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе Тимур Акулов үз чыгышында ислам диненә мөнәсәбәтнең бөтен җирдә бер дәрәҗәдә булмавын, кайдадыр исламның террорчылык белән тәңгәлләшүенә басым ясады һәм: «Мондый форумнар ярдәмендә бүгенге көн проблемаларын билгеләп, аларны чишү юлларын күрсәтсәк иде», – диде.

**Ахыры 2нче биттә.**

## Бәйрәмнәребез

# Корбан гаете мөбарәк булсын!

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Быел Корбан гаете 6 ноябрьгә туры килә. Әлеге көн рәсми рәвештә ял көне дип игълан ителде.

Республиканың барлык мәчетләрендә сәгать җидедә иртәнге намаз укыла, сигезенче яртыда бәйрәм вәгазе башлана, ә тугызынчы егерме минутта – Гает намазы. ТР мөселманнары Дини нәзарәтенең Голәмәләр шурасы тәкъдим иткән үрнәк вәгазьдә әйтелгәнчә, «бу изге көндә күк капуслары ачык була, барлык фәрештәләр, Аллаһтан адәм балаларының гөнаһларын кичерүне сорап, изге тәсбихтә булалар. Бу изге таңда мәчет манараларыннан әйтелгән азан, кылынган изге гамәлләр хөрмәтенә Аллаһ рәхмәте илә галәм изге нур белән тула».



**Ахыры 2нче биттә.**

# Дөнья киңлегендә - дин

*Башы 1нче биттә.*

Пленар утырышны Россия Фәннәр Академиясенең Көнчыгыш кульязмалар институты директорының фән буенча урынбасары Станислав Прозоров ачып җибәрде. Аның «Исламны фәнни өйрәнү: проблемалар һәм перспективалар» дигән доклады катнашучыларда зур кызыксыну уятты. Шулай ук Гуманитар һәм культурологик тикшеренүләр институты профессоры Сейеда Джавада Мири (Тегеран шәһәре, Иран), Халыкара ислам университеты хезмәткәре Эльмира Әхмәтова (Куала-Лумпур шәһәре, Малайзия), Россия Хокук академиясенең Казан филиалы профессоры Айдар Хәбетдинов чыгышлары да игътибарны җәлеп итте.

1-2 ноябрь көнне «Россиядә исламны өйрәнүнең актуаль проблемалары», «Суфизм теориясе һәм практикасы», «Мөселман булмаган илләрдә мөселман кабиләләре», «Мөселман дөньясы сәнгате» кебек темаларга секцион утырышлар һәм «түгәрәк өстәл»ләр эшләде.

# Корбан гаете мөбарәк булсын!

*Башы 1нче биттә.*

Бу көнне мөселманнарга таныш-белешләр, күршеләр, туганнар белән күрешү, ачуланышкан кешеләрнең үзара килешүе, авыруларның, ятим һәм мохтаҗларның хәлен белү, дөньядан киткән туганнарыбызның рух-шәрифләренә багышлап дога кылу, каберләренә барып кайту да сәннәт һәм саваплы гамәлләрдән санала. Кылынган гыйбадәтнең әҗер-савабы гаять зур, шулай ук гөнаһ өчен дә газап зур булачак. Гыйбадәтләр арасында кылыныр өчен иң хәерлесе – корбан чалу.

Корбан гаете – бөтендөнья мөселманнарының зур бәйрәме. Ул һәр елда Зөлхиҗҗә аеның унынчы көнендә башланып, 3-4 көн дәвам итә. Бәйрәм көнне таңнан торып, госел коенып, гает намазын укырга мәчеткә бару, барганда һәм кайтканда, фәкыйрьләргә сәдака бирү тиеш.

Быел корбанлык сарык уртача 4 мең сум тора. Бу турыда Голәмәләр шурасы утырышында карар да кабул ителде. Казанда алтмышлап мәчет бар. Әмма аларның барысы да корбан чалу урыны була алмый. Корбан чалу өчен төп урын – шәһәр үзәгендәге «Мәрҗани» мәчетенә караган мәйдан. Дин әһелләре бирелә, санитар нормаларга туры килгән махсус урында, казанлыларга изге ниятләрен тормышка ашырырга ярдәм итәргә әзер. Тагын бер махсус урын бар. Анысы – Бертуган Петряевлар урамында. «Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов әйтүенчә, быел шәһәрдә корбан 3-4 урында гына чалыначак. 6 ноябрьдә өлгермәгәннәр 7, 8 ноябрь көннәрендә дә әлеге изге гамәлне үти ала.

# Нәниләр «студент» булды

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

31 октябрь көнне КФУның уникаль проекты булган «Балалар университеты»ның 500гә якын «кечкенә студенты» беренче лекцияләрен тыңларга җыелды. Бу вакыйганың ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнен балаларның, әти-әниләрнең, әби-бабайларның кызыксынудан янып торган күзләре сөйли иде.

Тарих фәннәре докторы, профессор Рамил Хәйретдинов тарафыннан презентация формасында әзерләнгән лекцияне балалар бик зур игътибар белән тыңладылар. Профессор абыйлары аларга бу темага караган төрле-төрле слайдлар (Казан Кремле турындагы китап һәм кульязмаларга, Кремль музееның кыйммәтле экспонатларына, археологлар тормышына бәйле материалларга һ.б. нигезләнеп эшләнгән), Кремль турында вертолёттан төшерелгән видеоролик һәм «Казан Кремленә сәяхәткә килсәгез, сез нәрсәләр белә аласыз?» дип аталган видеофильм да күрсәтте.

Галим-укытучы, балаларга аңлаешлы һәм кызыклы итеп сөйләве белән бергә, аудиторияне гел җанландырып торды. Аның ярдәмчеләре – студент-модераторлар сораулары булган яисә җавап бирергә җыенган «кечкенә студентлар»га микрофоннарны тиз арада илтеп тордылар. Укытучы да сорауларның иң уйландыра һәм эзләнергә этәрә торганнарын гына сайлаган: «Казан Кремле турында сез ниләр беләсез?», «Археологлар – кемнәр алар?», «Татарстанда нинди тарихи һәйкәлләр бар?» һ.б.

Лекция ахырында Р.Хәйретдинов «кечкенә студентлар»ының материалны ни дәрәҗәдә үзләштерүләрен дә тикшереп алды. Балалар экрандагы слайдларда лекция сүзлегенә кертелгән тәрәк сүзләр ярдәмендә җавап бирделәр. Ә иң яхшы җавапларга Татарстан тарихына караган китаплар бүләк итеп бирелде.

# «Үткәнен белгәннең генә киләчәге бар»

**Рәдифә ШӘФЫЙКОВА,**
ksu.ru сайты хәбәрчесе

Әлеге сүзләрне еш ишетергә туры килә. 28 октябрь көнне Казан федераль университетында алар аеруча еш яңгырады. Бу көнне университет Польшадан килгән зур кунакларны кабул итте.

Польшаның Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Войцех Зайончковски җитәкчелегендәге делегация составында илче киңәшчесе Адам Садовник, публицист, профессор Ежи Борейша, Россия Фәннәр Академиясе каршындагы Польша Фәннәр Академиясе вәкиле Петр Глушковски бар иде.



Рәсемдә Войцех Зайончковски



Алия Галимуллина фотолары

Чара ректор Илшат Гафуров белән очрашудан башланып китте. Монда ике арадагы хезмәттәшлек, КФУ базасында ачылачак Россия-Польша үзәге турында сөйләштеләр. Әлеге үзәк эшчәнлеге телне өйрәнү, мәдәниятне пропагандалауга гына кайтып калырга тиеш түгел, эшмәкәрлекне үстерүгә басым ясарга да тиеш булачак.

Кунакларны тантаналы рәвештә Актлар залында каршы алдылар. Казан лингвистика мәктәбенә нигез салган Россия һәм Польшаның күренекле фән һәм җәмәгать эшлеклесе Бодуэн де Куртенэ истәлегенә мемориаль такта ачылды. Чарада ТР Премьер-министры Илдар Халиков, Мәгариф һәм фән министры Альберт Гыйльметдинов та катнашты. Тантананы ачып җибәргән ректор Илшат Гафуров Польшадан килгән кунакларга рәхмәт сүзләрен җиткерде. «Без Бодуэн де Куртенэны Казан университеты профессоры дип саныйбыз, ә поляклар аны үзләренеке дип исәпли. Ике як та хаклы – Бодуэн де Куртенэ ике ил арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерү өчен бик күп көч куйган кеше», – дип билгеләп узды. Бодуэн де Куртенэ – Казан һәм Казан университеты тормышында мөһим роль уйнаган шәхес. Ул Казан фәнни мәктәпләре үсеше һәм башкалабыз белән Польша хезмәттәшлегенең символлары булып тора. Бодуэн де Куртенэ дөньякүләм танылган Казан лингвистика мәктәбенә нигез салучы буларак кына түгел, университетыбызның дөньякүләм фәнни үзәк булып үсеп китүенә саллы өлеш кертүче галим дә. Войцех Зайончковски, үз чиратында, истәлек тактасын ачу Казан һәм Польша университетлары арасында мөнәсәбәтләрнең яңа сәхифәсен башлар дигән ышаныч белдерде.

«Бүгенге вакыйга миңа КФУны тәмамлаган кеше буларак та, республика халкының бер вәкиле буларак та бик сөенечле. Үткәнен онытмаган кешенең генә киләчәге бар», – диде ТР Премьер-министры Илдар Халиков. ТР Хөкүмәте башлыгы сүзләренчә, Казан федераль университеты алдында республиканың фән үсеше белән бәйле глобаль бурычлары тора. Аларга бөекгалимнәр тарафыннан салынган традицияләрне торгызу хисабына гына ирешеп була.

Истәлек билгесе рус, татар һәм поляк телләрендәге элмә тактаны һәм галим портреты белән барельефны үз эченә ала. Аны Польша скульпторы Александр Врублевский әзерләгән.

КФУның Көнчыгышны өйрәнү институты студентларына бәхет елмайды. Польшаның Россиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Войцех Зайончковски лекцияләр дә укыды.

**● Заман таләбе**

# Тәкъдимнәре кызыклы

**Гөлинә ГАЙНУЛЛИНА,**
Механика һәм математика
институты студенты

31 октябрь көнне «Уникс» бинасы үзенә Мәгълүмати технологияләр һәм хисаплау математикасы институтыннан, шулай ук Механика һәм математика институтыннан студентларны җыйды.





Алия Галимуллина фотолары

Биредә ИТ-парк җитәкчелеге белән очрашу үтте. Әлеге очрашуның максаты әйдәп баручы ИТ-компанияләр җитәкләгән зур проектлар өстендә эшләүдә катнашу мөмкинлекләре турында сөйләү; яңа мәгълүмати технологияләр белән таныштыру; үз эшен башларга теләүчеләргә ярдәм итү һәм юнәлеш күрсәтү.

Дөресен әйтергә кирәк, әңгәмә башланганчы очрашуга килгән студентларның ИТ-парк турында бик азы гына белә иде. Мондый зур компанияләр белән кызыксынуым көчле булмаганлыктан, алар арасында мин дә бар, тик әлеге очрашу шулкадәр җитди һәммәгънәле булып чыкты, хәтта ул, үз эшен башлап, булган мөмкинлекләрен сынап карарга куркып утыручы студентларны уянырга мәҗбүр иткәндер дисәм дә, ялгыш булмас.

Хәзер ИТ-паркның үзе белән якыннанрак танышыйк. Россия Федерациясенең Массакүләм коммуникацияләр һәм элемтә министрлыгы тарафыннан тормышка ашырылган ИТ-парк – «Россия Федерациясенең югары технологияләре нигезендә технопарклар оештыру» дип исемләнгән Дәүләт программасы кысаларында да барлыкка килгән беренче технопарк була. Әлеге ИТ-парк старт-ап һәм үсеп килә торган ИТ-компанияләргә югары дәрәҗәдә мөмкинлекләр тудыру максатыннан тормышка ашырыла. Бу уңайдан технологик продуктларны проектлаштыру һәм төзү, кулланылышка чыгару этапларында ИТ эшкәртү өчен кирәк булган барлык ресурслар белән тәэмин итү каралган: заманча технологияләр, җиһазлар һәм хезмәт күрсәтүләр, фәнни һәм ресурслы база һ.б. Заманча технологик инфраструктура ИТ-парк комплексындагы резидент-компанияләрнең ихтыяҗларын канәгатьләндерә һәм үз эченә түбәндәгеләрне ала: офис өчен биләмәләр, бизнес-инкубатор, конвенц-үзәк, бизнес-кунакханә һәм шулай ук технопаркның барлык инфраструктуралары төше булган мәгълүматлар эшкәртү үзәге.

ИТ-паркка яңа гына килеп кушылган кеше өчен беренче карашка бу мәгълүматлар, әлбәттә, бик катлаулы тоелыр. Ләкин яшь кешенең максаты яңалыкка омтылу булырга тиеш бит. Шуңа да һәр тудырылган мөмкинлектән файдаланып, үз мөмкинлекләребезне эшкә җигеп, авырлыклар алдында югалып калмыйча, алга атлыйк. Бу уңайдан ИТ-парк сезгә ярдәмгә килер.

● Ерактагы якын кардәшләр

# Фуртвангенда укуның ике атнасы

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Казанда югары белем алганнан соң, үзлегеннән немец телен өйрәнеп, быел Германиянең Фуртванген шәһәрендәге университетка имтиханнар тапшырып, хәзерге көндә беренче курста белем алучы сеңлемнең кызы Верониканың чит илдә укулары турында үзе теләп биргән көндәлегеннән кайбер битләрне тәкъдим итәбез.



■ *Вероника сабакташы белән*

**Германиядә татар студентлары ничек яши икән?**

***Вероника:*** «Бүген – 20 октябрь. Менә икенче атна көн дә иртә таңнан башта бер автобуста, аннан Голяйбахка кадәр электричкада, шуннан тагын автобуска утырып, яши торган шәһәрдән 30 чакрым ераклыктагы Фуртванген университетына укырга йөрим. Юлда 2 сәгать вакыт үтә. Тауларда беренче кар яткан».

***Хәбәрче шәрехләве:*** «Укырга йөрү Германиядә проблемалырак икән. Безнең студентлар юлга нибары 30-40 минут вакытларын сарыф итә. Ә кар әле көттерә, бу яктан калышабыз».

***Вероника:*** «Үткән атна университет белән танышу атнасы булды. Кайда, нәрсә, ничек икәнлекне аңлаттылар, сөйләделәр, күрсәттеләр. Безне укытачак галимнәр, укытучылар белән таныштырдылар. Тәртип бик каты, монда имтиханны бирә алмасаң, икенче мәртәбә килеп тапшыру юк, шунда ук укудан чыгаралар. Барыбызга да электрон карточкалар формасында студент билетлары бирделәр. Бу электрон карточкага акча салырга, ашханәдә ашаган өчен түләргә, китап сатып алырга була һ.б. Шулай ук, китапханәдә кирәкле дәреслек, китапларны (4 атнага кадәр бирәләр) шул электрон карточка ярдәмендә аласың (безнең университет китапханәсе иң байлардан санала). Бар да җайлы эшләнгән. Әгәр дә укып бетерергә өлгермәсәң, сайтка кереп, китапханә битендә куллану вакытын озайтырга була. Монда кирәкле китапны кайсы залдан, кайсы киштәдән табарга мөмкинлеге дә язылган».

***Хәбәрче шәрехләве:*** «Студентлар, бигрәк тә чит илләрдән, төрле төбәкләрдән килгәннәр белән бездә дә нәтиҗәле эш алып барыла. Имтихан тапшыруда бары тик бер генә мөмкинлек бирелү – начар. Бигрәк тә чит җирлеккә яраклашу чорында студентка авырга туры килә. Электрон карточкаларга килгәндә, алар безнең мәгариф системасына да кертелә башлады. Мәсәлән, кайбер мәктәпләребездә укучылар инде электрон кошелёк йөртә, шуның ярдәмендә төшке аш өчен түли. Студентларга да бу әйберне куллану начар булмаячак. Тик китап сатып алу ягын уйлап бетерәсе бар. Китапханәләр дә электронлашып бара».

***Вероника:*** «Безнең төркемдә барлыгы 66 студент: 6 кыз, калганнары егетләр. Бу атнада, бер-беребезне яхшырак белү, дуслашу һәм лидерларны билгеләү йөзеннән, урман белән капланган биек бер тау итәгендә җыелдык. Бик күңелле булды. Оештыручылар табигать белән бәйләнешле кызыклы, мәгънәле уеннар алдыннан әңгәмә үткәрделәр. Төшке аш урман эчендәге отель һәм кечкенә ресторан ролен үтәүче ике катлы бинада булды, вегетарианнар һәм итле ризык яратучылар өчен аерым әзерләнгәнлеге белән истә калды ул. Бу чара иртәнге 9дан кичке 4кә кадәр барды. Шул вакыт арасында төркемебезнең старостасын да сайларга тиеш идек. Ахырдан һәр кеше, үзе теләгән исемне язып, тартмага салды. Иң күп тавыш җыючы 32 яшьлек, өйләнгән, 2 бала әтисе, 10 ел армия сафларында хезмәт иткән ир кеше булды (мин дә аның исемен язган идем)».

***Хәбәрче шәрехләве:*** «Студентлар ял итә белә инде... Бездә дә калышмыйлар. Тик 32 яшьлек ир-атның һәм шул яшьтәгебашкастудентларның көндезге бүлектә белем алуы гына бераз елмайта. Бу яшьтәгеләрне безнең уку йортларында читтән торып уку бүлекләрендә генә очрата алырбыз».

***Вероника:*** «Көн дымлы булып, кояш елмаеп торса да, көзге салкын җил исә иде. Безгә гади целлофан пакетлар тараттылар һәм оекбашлар өстеннән киеп, бәйләп куярга куштылар. 5-6 кеше кушканча эшләдек. Өйгә кайткач карасам: кроссовкаларым юешләнеп беткән, ә аягым коп-коры һәм аз гына да туңмаган. Икенче көнне төркемебездән күбесе укырга килмәде, салкын тидерделәр бугай...»

***Хәбәрче шәрехләве:*** «Ә сәламәтлекне сакларга кирәк! Гәрчә Германия студентлары безнең илдә кулланылган алым белән үз-үзләрен сакласалар да! Әллә теге заманнарда безнең бабайлардан өйрәнеп калдылар микән?!

Шулай итеп, калышмыйбыз икән бит, җәмәгать! Алга китеш зур».

# «Беренче»ләр

**Ленар ХАММАТОВ,**
татар филологиясе бүлеге студенты

Җир йөзендә талантлы, сәләтле кешеләр бик күп. Менә шушы халыкның бер өлешен миңа да күрергә насыйп булды. Әйтерсең лә, аларны монда чүпләп китергәннәр.

28 октябрь көнне «Уникс» концертлар залында КФУның беренче курс студентлары үз бәйрәмнәренең гала-концертын уздырды. Бу – беренче курслар бәйрәме. Монда жюри тарафыннан сайлап алынган иң-иңнәре генә чыгыш ясады. Шушы бәйрәмгә без барыбыз да сентябрь аеннан бирле әзерләндек: беренче адым үзебезнең институтыбызда уздырылган факультетара концерт булса, икенче адым «Уникс»та үткән вузлар арасындагы концерт иде.

Бәйрәм КФУ ректоры И.Гафуровның тәбрикләү сүзләре белән тантаналы рәвештә башланып китте. Студентларның укырга да, шул ук вакытта ял итеп, менә шушындый чаралар үткәрергә дә вакытлары булуын хуплап, һәр эштә, һәр башлангычта уңышлар теләде ул.

Концерт җыр һәм биюләр белән үрелеп барды. Бигрәк тә халык биюләре игътибарны үзенә җәлеп итеп торды. Аерым милләтләрнең биюләре, аларның хәрәкәтләре үзенең милли үзенчәлеге турында сөйләгәндәй булды. Биючеләр күңелләрен биреп башкарды һәм максатларына ирештеләр дә: бөтен кеше икенче көнне дә әле аларны мактап бетерә алмады. Җырларга килгәндә, шуны билгеләп үтәсе килә: бөтен башкаручылар да, әле беренче курс студентлары гына булуларына карамастан, инглиз, француз һ.б. телләрдә оста җырладылар. Рус телендә дә ике җыр яңгырады. Татар җырлары булмады.

Үзебезнең институт кызларын һәм егетләрен күргәч, горурлык хисе кичердем. Ник дигәндә, алар, ничә турны үтеп, жюри тарафыннан сайлап алынып, бүген инде зур сәхнәдә чыгыш ясыйлар. Аларны әзерләгән укытучыларның тырышлыгы юкка китмәгән, димәк.

Концертны бирелеп карап-тыңлап утыргач, вакыт агышы сизелми икән. Мин үзем дә беренче курста белем алам. Икенче елга без бу бәйрәмне карый гына алачакбыз, катнашу инде мөмкин булмаячак. Шуңа күрә дә әйтәләрдер: иң кызыклы һәм кире кайтмас вакытлар – ул студент еллары, ә студентның иң шәп, күңелле чагы – ул беренче курстыр, мөгаен.

● Тел бәйгесе

# Океан артында да беләләр

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Университетыбызда рус телле студентлар өчен татар теленнән Республика вузара олимпиадасын үткәрү күркәм традициягә әверелде. Быел ул IV мәртәбә уздырылды. Биредә 7 югары уку йортыннан 81 студент катнашты.

Чараны Казан федераль университетының Филология һәм сәнгать институты директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов ачып җибәрде. Татар телен иң яхшы белгән студентларны сәламләп, республикабызның барлык ректорлары исеменнән котлады: «Соңгы елларда җитәкчелек тарафыннан телебезгә игътибар артуын сез дә сизәсездер. Күптән түгел вузара координация советы булдырылды. Ул вузларда татар телен укытуны контрольдә тотачак. Югары уку йортында татар телен укыту өчен, махсус бердәм программа, дәреслекләр булдырылыр, дип уйлыйбыз. Татар теленә булган хөрмәтегез өчен рәхмәт. Республикабызның киләчәге сезнең кулда. Телләр белү беркемгә дә зыян итмәс».

Кеше тормышында телләрнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнен һәркем аңлый. Күпмилләтле республикада яшибез, шулай булгач, бер-беребезгә хөрмәт, ихтирам тәрбияләү гаиләдән үк башланып, мәктәп елларында тагын да үстерелергә тиеш. Россия хокук академиясенең юридик факультетында белем алучы Марина Васильева Әлмәт шәһәреннән килгән. Татар мәктәбендә белем алган кыз татар телен «су урынына эчә». «Әти-әнием, әбибабайларым руслар. Гаиләдә дә, дусларым белән дә туган телемдә аралашам, ләкин татар теленең җыр кебек моңлы булуы мине таң калдыра. Олимпиадада, татар теленнән булган белемнәремне дөрес файдаланып, яхшы күрсәткечләргә ирешермен дип уйлыйм», – диде Марина. Укытучылары тел гыйлеме һәм чит телләр кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы Малик Хәйруллин да безнең әңгәмәгә бик теләп кушылды: «Кешедә, иң беренче чиратта, теләк булырга тиеш. Бездә татар теле ярты семестр гына укытыла, шулай да мин студентларыма мөмкин кадәр күбрәк белем бирергә тырышам. Башта телгә карата булган начар карашны юкка чыгарам: кереш лекция укыйм. Аннары аларга сүз ясагыч кушымчаның нәрсә икәнлеге кызык түгел. Студентлар аралаша белергә тиеш, телне интенсив юл белән өйрәтергә кирәк. Дәрес театральләштерелсә, нәтиҗәсе тагын да яхшырак булачак», – диде галим.


Динә Камалова фотосы

Олимпиадада катнашучылар белемнәрен ике турда сынады. Лексик-грамматик һәм коммуникатив биремнәрне, текст белән эшләүне үз эченә алган язма турда студентлар грамматик яктан үзләрен тикшерсәләр, икенче турда аралашу ситуацияләренә бәйле сөйләшү булды. Кемдер XIX гасыр студентына, кемдер 2013 елда уздырылачак Универсиада волонтерына, кемдер вузга керергә теләүче абитуриентка әверелде. Укытучылар да эшсез утырмады. Тәҗрибә уртаклашу, фикер алышу максатында «Татар теленә өйрәтүнең актуаль мәсьәләләре» дигән темага «түгәрәк өстәл» эшләде.

Казан милли-тикшеренү техник университетыннан килгән укытучылар әлеге олимпиаданы үткәрү студентларда телгә карата зур кызыксыну, киләчәккә стимул уятканлыгын ассызыклады. «Менә без 4 ел инде призлы урыннар яулыйбыз. Җиңеп кайткан студентларга карап, башкалар да кызыксына башлыйлар», – дип фикерләре белән уртаклашты доцент Гөлзәрә Зиннәтуллина.

Татар теленең чит илләрдә, хәтта океан артында да таралыш алуы күңелне сөендерә. Америкадан килгән студент Гарри да катнашучылар белән татар телендә аралашты.

Министрлар кабинеты вәкиле Галимҗан Гыйльманов олимпиаданы «эффектлы чара» дип атады. «Татар әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү зур проблема булып тора. Сезнең арадан тәрҗемәчеләр дә үсеп чыгар әле. Минем әсәрләрне дә тәрҗемә итәрсез», – диде яраткан язучыбыз.

Тел белгән – илләр гизгән, дип юкка гына әйтмәгәннәр. Инглиз, француз, немец һәм башка чит телләрне белү беркемгә дә комачауламый. Бу – заман таләбе! Ләкин ана телен белмәү – зур хата. Русларның, башка милләтләрнең татар телендә аралашуын күреп, татар телендә сөйләшергә оялучы милләттәшләребез бераз уйлансыннар иде.

**Илһам канатында**



**Илнар ХАЖИЕВ** 1993 елнын 5 июнендә Саба районында дөньяга килә. Шигырьләр язарга ярата. Кечкенәдән ижатка гашыйк булып үсүе аны КФУнын Филология һәм сәнгать институтына китерә дә инде. Бүген ул тәржемә гыйлеме һәм мәдәниятара коммуникация бүлегендә I курста белем ала.

## *Әй, бензин!*

*Су белән йөрми машина,*
*Белмим, кайчан көйләрләр?*
*Бензин һаман артса болай,*
*Бар да тәпи җәяүләр.*

*Заправка янын үткәндә,*
*«Жу» итә йөрәкләрең!*
*Машинаңны газга көйләп*
*Бир идең кирәкләрен.*

*Велосипед алып куйсаң,*
*Мәсьәлә юк чишәргә.*
*Бензин салырга кушмый, тик*
*Кирәк педаль ишәргә.*

*Берәр ат алып җибәрсәң,*
*Печән-салам өясе.*
*Төшәр иде,шулай итсәк,*
*Бераз бензин бәясе.*

*Күтәрсеннәр, әйдә, ярар,*
*Соңыннан үкенерләр.*
*Җир астында нефть беткәч,*
*Ишәккә күченерләр!*

## *«Локомотив»!*

*Көн тудымы исә, яңа хәбәр,*
*Янә бәла, янә корбаннар.*
*Төрле яклап сыный ачы язмыш,*
*Ничек түзә дуслар, туганнар?*

*Сентябрь дә халык күңелендә*
*Тирән эзен уеп калдырды.*
*«Локомотив» очкан самолетны*
*Кисәкләргә бүлеп яндырды.*

*Газраилләр сынмас егетләрне*
*Яп-яшь килеш харап иттеләр.*
*Юкса алар үлем өчен түгел,*
*Җиңү өчен туган иделәр.*

*Юк, булырга мөмкин түгел иде*
*Каһәр суккан мондый чынбарлык.*
*Чәлпәрәмә килде яшь гомерләр,*
*Бир, Ходаем, көчләр чыдарлык.*

*Команданың мәңгелек исемен*
*Югалтмаслар, аңа шигем юк.*
*Боз шаулатып тагын хоккей уйнар*
*Яңа яшь «бөркетләр» быел ук.*

*Аэропортта чәчәкләр сибелгән,*
*Хоккейчылар инде күмелгән...*
*Авыр туфрагыгыз җиңел булсын,*
*Сез чыкмассыз безнең күңелдән!*

**Халәт**

**Римма ИГДЕЕВА,**
татар филологиясе бүлеге студенты

# Никах туе - күкләр фатихасы



Кеше тормышында иң җаваплы адым – үз гаиләңне кору. Мөселман халкы гаилә коруны ике яшь кешегә никах укыту белән башлый.

Элек-электән үк инде никахны өйгә мулла чакыртып, шаһитләр каршында укыганнар. Бүгенге көндә яшьләрнең дә, җәмгыятьнең дә никах укытуга мөнәсәбәте үзгәрде. Аны инде ата-баба йоласы итеп түгел, ә ниндидер матур күренеш буларак кына үткәрәләр. Никахны үз өеңдә укыту авыл җирләрендә генә калып бара. Хәзер аны мәчетләрдә укыталар.

Мәчетләрдә махсус никах уку мәҗлесләрен уздыру елдан-ел арта бара. Хәзер бу бәйрәмне уздыру өчен, Казан мәчетләренә авыллардан да киләләр. Никах табыны өчен хәләл ризыклар әзерләүче ашханәләр дә ишәеп китте. Кемнәр өчендер бу яңа гаилә кору мәҗлесе булса, кемнәрдер моңа бизнес буларак карый. Интернет челтәрендә дә бу өлкәдә мәчетләрнең хезмәт күрсәтүен тәкъдим итәләр.

«Кол-Шәриф» мәчете яшьләр арасында никах укыту буенча беренче урында. Мәчет Казанның нәкъ үзәгендә урнашкан, матур, мәһабәт бина. Никах укыган өчен түләү ирекле: кем күпме сәдака бирә. Монда алдан килеп язылырга кирәк. Шулай ук «никах мәҗлесенә профессиональ фотограф та дәшергә була», дип әйтелгән.

Икенче урында – «Сөләйман» мәчете. Монда да алдан килеп язылырга кирәк һәм никах туена 10-15 кешене генә чакырырга тәкъдим ителгән. «Болгар» мәчетендә хәтта булачак килен белән кияүгә чакыру кәгазе дә биреп җибәрәләр икән.

«Мәрҗани» мәчетендә никах уку өчен ике зал бар: берсе – зур, икенчесе – кече зал. Кунакларның санына карап, бу залларда яшьләргә никах укыйлар. «Әҗем» мәчете дә яшьләр арасында үзенә күрә бер урын алып тора. Биредә никах мәҗлесенә унга якын гына кунак чакырырга тәкъдим ителә.

Бу мәчетләрнең һәрберсенең тарихы бай, эчке ягы да, тышкы ягы да бик матур, шуңа күрә дә яшьләр арасында алар бик «популяр» санала.

Әйе, һәркемнең үз гомерендә бер генә була торган бу мизгелне матур, истәлекле итеп үткәрәсе килә. Әмма безнең максатыбыз бит бу түгел, ә киләчәктә бәхетле, тату гаилә корып, таза балалар үстереп, иңгә-иң куеп яшәү булырга тиеш.

**Минем урамым Казан урамын**

**Лилия БӘДРЕТДИНОВА,**
хәбәрче

# Черек күл

Һәрберебез ял итәргә ярата. Кемдер үзе генә күңел ачарга чыкса, берәүләр (бүгенгечә матур итеп әйтсәк) компания белән ял итә.

Яшьләрнең аеруча да яраткан урыны булып Черек күл санала. Әлеге парк башкалабызның нәкъ үзәгендә урнашкан булса да, шәһәр шау-шуы бу урынны читләтеп үтә, миңа калса.

Елның кайсы гына фасылында да парктагы табигать искиткеч матур. Җәен велосипед-роликларда йөрсәң, кышын чана-чаңгы, тимераякта шуар өчен дә уңайлыклар булдырылган.

Паркта зур булмаган күл бар. Җәен анда кыр үрдәкләре күп була. Тагын шунысы игътибарга лаек: әлеге паркка Лобачевский урамы ягыннан кергәндә, зур, ак төскә буялган арка аша үтәсең. Ул «Гашыйклар аркасы» дип атала. Арканың бер ягына егет, икенчесенә кыз басып, бер-берсенә матур сүзләр пышылдаса, тавыш дулкыннары арка буйлап иясенә барып җитә, ачык аңлашыла.



Энҗе Ибраһимова фотосы

Парк Казанның меңъеллыгына төзекләндерелгән иде, шуннан бирле аңа кагылучы юк. Быел әле Черек күл урынына машиналар кую өчен парк төзеләчәк, дигән имеш-мимешләр дә йөрде. Шәһәр халкы, студентлар, митингка чыгып, әлеге матур, табигатьнең гүзәл бер почмагын саклап калуга ирештеләр.

Шәһәр үзәгеннән читкә чыкмыйча гына ял итәргә теләсәгез, Черек күлгә рәхим итегез!

P.S. Черек күл төрле елларда бик күп тарихи вакыйгаларның шаһите булган. Аның бай үткәне турында алдагы саннардан укып белерсез.

**Студент эш эзли**

# «Елга ике тапкыр чит илдә ял ит!»



**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

«Тиз арада уныш яулап аласыгыз киләме? Елына ике тапкыр чит илгә ял итәргә барырга хыялланасызмы? Керемнәрегезнең чыгымнарыгыздан 50% ка артык булуын телисезме? Әгәр дә барлык сорауларга да җавабыгыз уңай икән, түбәндәге номерга шалтыратыгыз. Әгәр дә юк икән, барыбер шалтыратыгыз».

Университетка барышлый беркөнне шундый баналь эчтәлекле белдерүгә юлыктым. Игътибар итмәслек тә түгел, ул күзгә бәрелеп торырлык төсле кәгазьгә язылган иде. Мондый белдерүләрдә дөрес мәгълүмат булмаганын чамалыйм да, беләм дә кебек, шулай да нинди эш тәкъдим итәрләр икән соң?! Кызыксынуымны беркадәр азарт биләп алды һәм шушы белдерүдәге номерга шалтыратырга булдым. Мөлаем тавышлы туташ, исем-фамилиямне белешкәч, сөйләшү манерамның бик матур булуын искәртеп үтте һәм миңа, һичшиксез, аларның офисына килергә кирәклеген әйтте. Мин инде бирешмичәрәк кенә, бернинди белемсез аласызмыни, нинди эш соң ул, дип сорап карыйм. Эшем бик җитди икән: офиста кәгазьләр тутырачакмын. Борчылырга урын булмаганлыгын да әйтеп узды «мөлаем тавыш», чөнки мин эш тәртибен, бик тиз «эләктереп алучы кешегә» охшаганмын икән. Мәгълүматны телефоннан аңлатуы кыен булганга, мин, һичшиксез, офиска барырга тиешмен. Ярар соң, бер башлагач дип, тәвәккәлләдем дә Таҗи Гыйззәт урамында урнашкан «булачак эш урыныма» киттем. Бина үзе бик матур күренә, әйләнә-тирәдә «деловой-деловой» кешеләр чабышып йөри. Кирәкле кешемә шалтыраткач, ул мине төшеп алды. Сөйләшә башлаганчы, миңа теркәлү узарга кирәк икән, ә ул нибары 250 сум. Тешләремне кысып, «студент кошелёгы»мнан барлы-юклы 250 тәңкәмне алып, матур тавышлы кызга суздым. Ничек инде, минәйтәм, бернинди аңлатусыз теркәлү, дим. «Сез инде эшкә кабул ителгән диярлек, бары тик бездә көндәшлек зур, һәр секундыбыз санаулы. Сезнең урынга башка берәүне алмасыннар дип тырышабыз», – дип, мине әллә ничек кенә гипнозлап куйды бу. Тыныч кына тыңлап утырам: бик күп акча алачакмын, гел күтәрелүләр булачак, һәм мин шул вакантлы урынга нык туры киләм икән. Әкиятнең әкияте дип, эчтән түзеп утырам. Ярар, алга таба нишләтерләр икән? Йөгереп йөрүче халыкка тәрәзәдән күз салам: чынлап та шунда эшлиме икән болар?! Тәмләп сөйләп бетергәч, миңа килешү сузды. Килешүнең шартлары буенча мин, нибары 15 меңгә якын акчамны сарыф итеп, курслар узарга тиешмен. Ә аннан соң килешүдә язылган ниндидер адрес буенча барып, үз эшемә керешә алам икән!.. Матур тавышлы кыз һаман ручкасын суза... Юк инде, шушы урында уенны туктатырга булдым. Уйлап бетерермен дигән сылтама белән тизрәк чыгу җаен карадым.

Соңрак белешеп бетердем: бу офис бинасы бөтенләй башка тармакныкы икән. Һәм анда эшләүчеләр, кыскартуга эләгеп, үзләре эшсез калганнар. Ә белдерү бирүчеләр бу бинада бер бүлмәне арендага гына алып торганнар.

Мондый капкыннарга эләгүчеләр, чыннан да, бик күп бит. Әз генә баш мие кыйпылчыкларын эшләтеп карасаң, нинди тәҗрибәле хезмәткәр үз офисына эшчеләрне урам баганаларына белдерүләр ябыштырып эзләсен ди инде?! Статистика буенча, алданучылар еш кына 19-23 яшьлекләр икән. Чөнки, үзегез беләсез, без – яшьләрнең уенда күп итеп һәм тиз арада акча эшләү. Ә мондый типтагы алдавыч-белдерүләрнең, киресенчә, кесә юкартуның бер ысулы икәнен уйлап та карамыйбыз. Җиңел юл белән баеп киткән кешеләр заманча телесериалларда гына була. Ә яхшы эш ул беркайчан да җирдә аунап ятмый. Бары мәгънәле, күңелгә ятышлы эш кенә җанны җылытып торачак!

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

Тираж 999

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, Л.Н.Бәдретдинова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты

Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Сул Болак ур., 44 й., 6 Б каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: (843) 292-22-91, 89053711571.
Электрон почта: tggpu-tat@yandex.ru. Сайт: ksu.ru

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.

Газета бушлай таратыла